ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ______________ с. Верхний Услон КАРАР ______________

Югары Ослан муниципаль районында
Гражданнарны контракт буенча хәрби
хезмәткә сайлау турында

"Хәрби хезмәт һәм хәрби бурыч турында" 1998 елның 28 мартындагы Федераль законның 53 ст. нигезендә, «Контракт буенча хәрби хезмәткә күчерелгән сержантлар һәм солдатлар вазыйфаларын комплектлау системасын камилләштерү һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләре, башка гаскәрләр, хәрби формированиеләр һәм органнар сержантлары (старшиналары) шулай ук хәрби–диңгез флоты диңгезчеләре вазыйфаларын комплектлауга күчүне гамәлгә ашыру" федераль максатчан программа турында Россия Федерациясенең 18 08.2008 елдагы 621 номерлы ФЗ карарын үтәү йөзеннән Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 1 нче кушымта нигезендә Югары Ослан муниципаль районы буенча контракт буенча хәрби хезмәткә туплау комплектын исәпләүне расларга.

2. Татарстан Республикасы хәрби комиссарына тәкъдим итәргә

Югары Ослан районы буенча авыл җирлекләре башлыклары белән берлектә:

- запаста торучы, 19 яшьтән 40 яшькә кадәрге, контракт буенча ирекле нигездә хәрби хезмәт узу өчен сәламәтлеге торышы буенча яраклы гражданнарны җыю эшен оештырырга;

- Югары Ослан муниципаль районында яшәүчеләр белән контракт буенча хәрби хезмәткә кандидатлар җыю буенча агитация-пропаганда эше алып барырга;

- контракт буенча хәрби хезмәт үтәргә теләк белдерүчеләрне исәпкә ала;

- ирекле нигездә ачыкланган кандидатларны контракт төзү турында карар кабул итү өчен Югары Ослан районы буенча Татарстан Республикасы хәрби комиссариатына җибәрергә;

- ай саен авыл җирлекләрендә хәрби исәпкә алу өчен җаваплы булып, 4 нче кабинетка Татарстан Республикасы хәрби комиссариатына контракт буенча хезмәт итүгә кандидатлар турында белешмәләр тапшырырга.

3. Дәүләт бюджет учреждениесенә Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге

Югары Ослан районы (алга таба халыкны эш белән тәэмин итү үзәге) халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең һәм Югары Ослан районы буенча Хәрби комиссариатның уртак эшчәнлеге турындагы килешү нигезендә:

- халыкны эш белән тәэмин итү үзәгендә исәптә торучы гражданнарга Югары Ослан районы буенча хәрби комиссариатта рядовой һәм сержант составы вазыйфасына контракт буенча хәрби хезмәткә җыю турында хәбәр итәргә;

- контракт буенча хезмәт итәргә һәм аларны Югары Ослан районы буенча хәрби комиссариатка җибәрергә теләк белдергән гражданнарга социаль гарантияләрне һәм ташламаларны аңлатырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль-мәдәни мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.С. Хәкимҗанов

Югары Ослан муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкченең
____________ 2017 ел № ____ карарына

1 нче кушымта

Авыл җирлекләре буенча контракт буенча хәрби хезмәткә туплау комплектларын Исәпләү

| № п/п | АҖ исеме | Контракт буенча хәрби хезмәткә сайлауга бирем |
|---|---|---|
| 1 | Олы Мәми | 1 |
| 2 | Яңа Рус Мәмәтхуҗасы | 1 |
| 3 | Бурнаш | 1 |
| 4 | Канаш | 1 |
| 5 | Түбән Ослан | 1 |
| 6 | Килди | 1 |
| 7 | Куралово | 1 |
| 8 | Шеланга | 2 |
| 9 | Макыл | 2 |
| 10 | Соболевское | 1 |
| 11 | Введенский Бистәсе | 1 |
| 12 | Яр буе Морквашы | 1 |
| 13 | Мәйдан | 1 |
| 14 | Вахитов | 1 |
| 15 | Ямбулат | 1 |
| 16 | Октябрьский | 1 |
| 17 | Печище | 1 |
| 18 | Карагуҗа | 1 |
| 19 | Югары Ослан | 1 |

Башкарма комитетның эшләр белән идарә итүче А.К. Минһаҗева